**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 4 октябрь

№ 716

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 67 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 67 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Планнан тыш контроль чаралар түбәндәге очракларда кабул ителгән Министр карары нигезендә гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, хокук саклау органнары мөрәҗәгатьләре (йөкләмәләре), депутатлар сораулары, башка дәүләт органнары, гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләре керүгә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясе законнарын тиешле бозулар билгеләре ачыкланган очракта;

контроль чара өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәү барышында Министрлыкның эшчәнлек өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча закон актларын һәм башка норматив хокукый актларны бозулар турындагы мәгълүмат алган очракта, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан;

элегрәк бирелгән күрсәтмәне (тәкъдимне) үтәү вакыты чыккан очракта;

әлеге Тәртипнең 36, 45, 63 нче пунктларында каралган очракларда.»;

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, Министрлык түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке дәүләт финанс тикшерүе вәкаләтләрен:

Россия Федерациясе бюджет законнарының һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру турында, шул исәптән дәүләт йөкләмәләрен үтәү хакында хисаплылыкның тулы һәм дөрес булуын;

б) Килешү системасы турындагы федераль законның 99 статьясындагы 8 өлеш белән күздә тотылган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә карата эчке дәүләт финанс тикшерүен:

Килешү системасы турындагы федераль законның 18 статьясында күздә тотылган сатып алуларны нигезләүгә таләпләрнең үтәлешенә һәм сатып алуларның нигезләнгән булуын;

Килешү системасы турындагы федераль законның 19 статьясында күздә тотылган сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләре үтәлешен;

план-графикка кертелгән, бердәнбер кайтартучы (подрядчы, үтәүче) белән төзелә торган килешү бәясен, килешүнең башлангыч (максималь) бәясен нигезләүне;

кайтартучы (подрядчы, үтәүче) килешү шартларын бозган очракта, заказчының җаваплылык чаралары күрүен һәм башка гамәлләр кылуын;

кайтартылган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтнең килешү шартларына туры килүен;

кайтартылган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәтнең исәп-хисабын документларда үз вакытында тулы һәм дөрес итеп күрсәтелүен;

кайтартылган товардан, башкарылган эштән (аның нәтиҗәсе) яки күрсәтелгән хезмәттән файдалану сатып алуны гамәлгә ашыру максатларына туры килүен;

в) законнар белән күздә тотылган очракларда җирле бюджетлар үтәлешен тикшерүдә тотуны.»;

7 нче пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү, шулай ук алар тарафыннан дәүләт (муниципаль) программаларында күздә тотылган максатчан күрсәткечләргә һәм индикаторларга туры килгән әлеге акчадан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү өлешендә финанс органнары (бюджетара трансфертлар бирелгән бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр (эш итүчеләр) һәм аны алучылар);»;

«е» пунктчасында «Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр),» сүзләреннән соң «дәүләт контрактлары,» сүзләрен өстәргә, «Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр)» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре

белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, әлеге юридик затларның кыйммәтле кәгазьләренә бюджет акчасын урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын үтәү» сүзләренә алмаштырырга;

«к» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«к) гамәлләре Килешү системасы турындагы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алуны, эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән заказчылар, килешү хезмәтләре, килешү идарәчеләре, сатып алуларны гамәлгә ашыру комиссияләре һәм аларның әгъзалары, вәкаләтле органнар, вәкаләтле учреждениеләр, махсуслаштырылган оешмалар.»;

8 нче пунктта «бу Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «а» һәм «б» пунктчалары белән күздә тотылган» сүзләрен «Россия Федерациясе бюджет законнарының һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен тикшерүдә тоту вәкаләтләре, шулай ук Килешү системасы турындагы федераль законның 99 статьясындагы 8 өлеш белән күздә тотылган вәкаләтләр» сүзләренә алмаштырырга;

10 нчы пунктның «ж» пунктчасына «, шулай ук Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гамәлгә ашырылган сатып алуларны гамәлдән чыккан дип тану хакындагы» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 11.1 нче һәм 11.2 нче пунктлар өстәргә:

«11.1. Тикшерү объектларының вазыйфаи затлары, индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар түбәндәге хокукларга ия:

а) күчмә контроль чаралар үткәрүдә турыдан-туры катнашырга, контроль чаралар темасына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

б) Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр (ревизияләр) актлары, тикшеренүләр нәтиҗәләре белән танышырга, шулай ук үткәрелгән контроль чаралар нәтиҗәләре буенча язма дәгъвалар кертергә;

в) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Министрлык һәм аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерергә;

г) Министрлык һәм аның вазыйфаи затларының законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) китергән зыянны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каплау.

11.2. Тикшерү объектларының вазыйфаи затлары, индивидуаль эшмәкәрләр һәм физик затлар түбәндәгеләргә бурычлы:

а) җитәкченең, хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы башка вазыйфаи затлар яки затның вәкаләтле вәкиленең килүен тәэмин итү;

б) контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны үз вакытында һәм тулы күләмдә кертергә, шул исәптән Министрлыкның вазыйфаи затлары сораулары буенча;

в) Министрлыкның вазыйфаи затларына телдән һәм язма аңлатмалар бирергә;

г) тикшерү (ревизия) төркеме составына керә торган вазыйфаи затларга, җәлеп ителә торган белгечләргә һәм экспертларга оештыру һәм техника ягыннан кирәкле

булышлык күрсәтергә, шул исәптән документлар һәм материалларның сакланышы максатында, аларны эш бүлмәләре белән тәэмин итәргә;

д) тикшерү (ревизия) төркеме составына керә торган вазыйфаи затларның тикшерү объектлары биналарына һәм территорияләренә каршылыкларсыз керә алуын тәэмин итәргә, товарларны, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләрен күрсәтергә;

е) тикшерү (ревизия) төркеме составына керә торган вазыйфаи затларның башка законлы таләпләрен үтәргә, шулай ук әлеге затлар үзләренең хезмәт вазыйфаларын башкарганда, аларның законлы эшчәнлегенә каршы чыкмаска;

ж) тәкъдимнәр, күрсәтмәләр таләпләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

з) бухгалтерлык (бюджет) исәбенең һәм закон актларында һәм башка норматив хокукый актларда каралган документларның мәгълүматлары сакланышын тәэмин итәргә;

и) контроль чаралар кысаларында җәлеп ителә торган белгечләр һәм экспертларның биналарга, территорияләргә, шулай ук тикшеренү, экспертиза объектларына (предметларын) керә (файдалана) алуын тәэмин итәргә;

к) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында күздә тотылган башка бурычлар үтәргә.»;

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Өстәмә тикшерүләр күчмә яки камераль тикшерүләр өчен шул ук эзлеклелектә билгеләнгән тәртиптә билгеләнә һәм үткәрелә. Өстәмә тикшерүләр үткәрү вакыты 20 эш көненнән артыграк була алмый. Өстәмә тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә, ул күчмә яки камераль тикшерү материалларына шул ук эзлеклелектә теркәлә. Өстәмә тикшерү нәтиҗәләре буенча өстәмә тикшерү объектына тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр җибәрелми.»;

30 нчы пунктта «Министр боерыгы белән рәсмиләштерелә» сүзләреннән соң «, һәм анда контроль чараны туктатып тору (яңадан башлау) сәбәпләре күрсәтелә» сүзләрен өстәргә;

36 нчы пунктка «тикшерү үткәрүне» сүзләренә кадәр «планнан тыш» сүзен өстәргә;

37 нче пунктка «, өстәмә тикшерүләр барышында» сүзләреннән соң «Министрлык файдалана торган мәгълүмат системалары мәгълүматларын анализлау нәтиҗәсендә.» сүзләрен өстәргә;

40 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40. Тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең мотивлаштырылган мөрәҗәгате нигезендә Министр тикшерү үткәрүне билгеләргә мөмкин.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча камераль тикшерү материалларына теркәлә торган бәяләмә төзелә.»;

43 нче пунктта:

беренче җөмләдә «биш көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

икенче җөмләдә «Тикшерү объектының» сүзләрен «Контроль объектының» сүзләренә алмаштырырга;

45 нче пунктның «в» пунктчасына «күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү» сүзләренә кадәр «планнан тыш» сүзләрен өстәргә;

46 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«46. Күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү контроль объекты урнашкан урын буенча контроль объектына карата тиешле тикшерү эшләрен гамәлгә ашырудан һәм күчмә тикшерү актын төзүдән тора.»;

47 нче пунктта «күчмә тикшерү (ревизия)» сүзләрен «контроль объекты урнашкан урын буенча тикшерү эшләре» сүзләренә алмаштырырга;

48 нче пунктта сүзләрен «контроль объекты урнашкан урын буенча тикшерү эшләре» сүзләренә алмаштырырга;

49 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«49. Тикшерү (ревизия) төркеменең контроль объекты территориясенә яки бинасына керүенә каршы чыкканда, шулай ук контроль объектының вазыйфаи затлары күчмә тикшерү (ревизия) үткәргәндә соратылган мәгълүматны, документларны һәм материалларны бирмәү яки үз вакытында бирмәү фактлары буенча тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесе Министрлык раслый торган форма буенча акт төзи.»;

51 нче пунктның беренче абзацына «нигезендә» сүзеннән соң «күчмә тикшерү (ревизия) кысаларында тикшерү эшләре үткәрү барышында кирәкле мәгълүматны (документларны, материалларны) алу мөмкин булмаган очракта» сүзләрен өстәргә;

53 нче пунктта:

беренче җөмләне төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Контроль объектының эшчәнлеген фактта өйрәнү буенча тикшерү эшләрен үткәрү һәм аларның нәтиҗәләре нигезендә тиешле актлар төзелә.»;

54 нче пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) контроль объектының бухгалтерлык (бюджет) исәбе булмаганда яки контроль объекты бухгалтерлык (бюджет) исәбен алып бару кагыйдәләрен бозганда, һәм аның нәтиҗәсендә алга таба тикшерү (ревизия) үткәрү мөмкин булмаса – контроль объекты тарафыннан күчмә тикшерү (ревизия) үткәрү өчен кирәкле документларны торгызу, шулай ук контроль объекты тарафыннан исәпкә алу һәм хисаплылык документларын тиешле хәлгә китерү чорында;»;

түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасы өстәргә:

«ж) тикшерү (ревизия) төркеменә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында алга таба тикшерү (ревизия) үткәрү мөмкин булмаслык хәлләр булганда, каршы тора алмаслык көч аркасында килеп чыкан хәлләрне кертеп.»;

55 нче пунктта «аның вакыты өзелә» сүзләрен «контроль объекты урнашкан урын буенча тикшерү эшләре үткәрү вакыты өзелә, ләкин күп дигәндә 6 айга» сүзләренә алмаштырырга;

61 нче пунктның беренче җөмләсендә «биш көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

64 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«64. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «а» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Министрлык:

а) карап тикшерү өчен мәҗбүри булган Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив

хокукый актлар буенча ачыкланган бозулар, Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр), дәүләт контрактлары шартларын, дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, Татарстан Республикасы бюджеты акчасын контроль объектларының кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозулар хакында мәгълүматны, шулай ук әлеге документта билгеләнгән вакытларда карап тикшерү өчен мәҗбүри булган мондый бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын бетерү чараларын күрү турында таләпләрне яки бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасын кире кайтару хакында таләпләрне үз эченә алган тәкъдимнәр җибәрә;

б) күрсәтмәдә күрсәтелгән вакытларда үтәү өчен мәҗбүри булган Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны бозуларны, Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр), дәүләт контрактлары шартларын, дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын, Татарстан Республикасы бюджеты акчасын контроль объектларының кыйммәтле кәгазьләренә урнаштыру максатларын, тәртибен һәм шартларын бозуларны бетерү турындагы таләпләрне һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджетына китергән зыянны каплау хакында таләпләрне үз эченә алган күрсәтмәләр җибәрә;

в) бюджет мәҗбүр итү чараларын куллана.»;

65 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«65. Әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «а» пунктчасының дүртенче – унынчы абзацларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Министрлык Россия Федерациясе законнарын һәм сатып алулар өлкәсендә килешү системасы турындагы башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр җибәрә. Шул ук вакытта әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктындагы «а» пунктчасының дүртенче – алтынчы абзацларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында бу күрсәтмәләр сатып алу башланганчы бирелә.»;

67 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«67. Тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр, аларны җибәрү турындагы карар кабул ителгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә контроль объекты вәкиленә бу Тәртип нигезендә җибәрелә (тапшырыла).»;

77 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«77. Хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр контроль чараларны үткәрү нәтиҗәләре турындагы хисап Министрга кертелә.».

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы ундүртенче абзац 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин